МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2020 г. Казань № под-369/20

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин итүләргә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезендә боерык бирәм:

1. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин итүләргә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин итүне оештыру турында» 2014 елның 17 мартындагы 1367/14 номерлы;

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урын бирүгә мохтаҗлар буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 18 ноябрендәге 6575/14 номерлы;

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 18 ноябрендәге 6575/14 номерлы боерыгы белән расланган Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урын бирүгә мохтаҗлар буларак исемлеккә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 22 июнендәге под-1247/16 номерлы;

«Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 4 сентябрендәге под-9242/15 номерлы.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары А.М. Әсәдуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары –
министр

Р.Т.Борһанов

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2020 елның 11 мартындагы под-369/20 номерлы боерыгы белән расланды

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – дәүләт хезмәте) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедураларның (гамәлләрнең) вакытларын һәм эзлеклелеген, мөрәҗәгать итүчеләр, дәүләт хакимияте органнары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр:

социаль найм килешүләре буенча торак урыннарны наймга алучы затлар яки социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алган гаилә әгъзалары яки торак урыннарның милекчеләре булып тормаган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар (алга таба – ятим балалар), шулай ук социаль найм килешүләре буенча торак урыннарны наймга алучылар яки социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алган гаилә әгъзалары яки торак урыннарның милекчеләре булган ятим балалар, әгәр алар тарафыннан элегрәк билгеләнгән торак урыннарда аларның яшәве Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы яисә, мондый торак урын урнашкан территориянең Россия Федерациясе субъекты законында тиешле вәкаләтләр бирелгән очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән тәртиптә мөмкин түгел дип танылган булса;

социаль найм килешүләре буенча торак урыннарны наймга алучы булып яки социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алган гаилә әгъзалары булып яки торак урыннарның милекчеләре булып тормаган ятим балалар исәбендәге затлар, шулай ук социаль найм килешүләре буенча торак урыннарны наймга алучылар яки социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алган гаилә әгъзалары яки торак урыннарның милекчеләре булып торган ятим балалар исәбендәге затлар, әгәр алар тарафыннан элегрәк билгеләнгән торак урыннарда

аларның яшәве Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органы яисә, мондый торак урын урнашкан территориянең Россия Федерациясе субъекты законында тиешле вәкаләтләр бирелгән очракта, җирле үзидарә органы тарафыннан әлеге Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән тәртиптә мөмкин түгел дип танылган булса;

кайчандыр ятим балалар категориясенә караган, 23 яшенә җиткән һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә социаль найм килешүе буенча торак урыннар белән чиратсыз тәэмин ителү хокукына ия булган, билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар яки торак урынга мохтаҗлар буларак исәпкә куелмаган һәм 2013 елның 1 гыйнварына әлеге хокукны гамәлгә ашырмаган яки 2013 елның 1 гыйнварыннан соң махсуслаштырылган торак урыннарның найм килешүләре буенча махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин итүгә хокуклы, ләкин исемлеккә кертелмәгән затлар.

1.2.1. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән затларны яшәү урыны буенча исемлеккә кертү турында гаризаны түбәндәгеләр тапшыра:

а) 14 яше тулган ятим балаларның законлы вәкилләре, – алар бу яшькә җиткән көннән соң яки «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясының 1 пунктында каралган торак урыннарны бирү нигезләре барлыкка килгән вакыттан башлап 3 ай эчендә;

б) балигълык яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алган ятим балалар, әгәр алар тулысынча хокукка сәләт алганчыга кадәр билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән булса;

в) ятим балалар исәбендәге затлар, әгәр алар балигълык яшенә яки 18 яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алганчы билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән һәм торак урыннар белән тәэмин ителүгә үз хокукларын гамәлгә ашырмаган булса;

г) 23 яшенә җиткән затлар, әгәр алар торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар яки торак урынга мохтаҗлар сыйфатында билгеләнгән тәртиптә исәпкә куелмаган булса яки исемлеккә кертелмәгән һәм торак урыннар белән тәэмин ителүгә үз хокукларын гамәлгә ашырмаган булса;

д) ятим балалар исәбендәге, эшкә сәләтсез яки чикләнгән рәвештә генә эшкә сәләтле затларның, 23 яшенә җиткән һәм билгеләнгән тәртиптә исемлеккә кертелмәгән һәм торак урыннар белән тәэмин ителүгә үз хокукларын гамәлгә ашырмаган затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр);

е) законлы вәкилләре гариза тапшырмаган очракта, әлеге балаларга карата үз вәкаләтләрен башкара торган опека һәм попечительлек органнары ятим балаларны исемлеккә кертү турындагы гаризаны әлеге пунктның «а» пунктчасында каралган тәртиптә һәм вакытта, «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясының 3 пунктындагы өченче абзацында билгеләнгән вакыт узып киткән көннән соң 30 эш көне узганчы тапшыра.

1.2.2. Ятим балаларның яшәү урыны үзгәргәндә, законлы вәкилләр аларны Россия Федерациясенең башка субъектында элеккеге яшәү урыны буенча исемлектән төшереп калдыру һәм ятим балаларның яңа яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына (алга таба – яңа яшәү урыны буенча орган) аларны Татарстан Республикасында яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү турында язма формадагы гариза белән мөрәҗәгать итә.

Балигълык яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алган ятим балалар, ятим балалар исәбендәге затлар, әгәр аларның законлы вәкилләре алар балигълык яшенә җитмичә яки 18 яшенә җиткәнчегә тулысынча хокуклылык алганчы мондый гариза белән мөрәҗәгать итмәгән булса, үзләрен Татарстан Республикасындагы яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү һәм Россия Федерациясенең башка субъектында элеккеге яшәү урыны буенча исемлектән төшерү турында гариза белән мөстәкыйль мөрәҗәгать итә ала.

Татарстан Республикасындагы яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү һәм Россия Федерациясенең башка субъектында элеккеге яшәү урыны буенча исемлектән төшереп калдыру турында гариза белән законлы вәкилләрнең Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә гамәл кылучы вәкилләре, балигълык яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алган ятим балаларның вәкилләре, ятим балалар исәбендәге затларның вәкилләре (алга таба – ышаныч кәгазе буенча вәкилләр) мөрәҗәгать итә ала.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлык урнашкан урын:

420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 йорт (канцелярия, юридик бүлек, дәүләт программаларын һәм проектларын гамәлгә ашыру бүлеге),

420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 3, 207 кабинет (опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге).

Министрлыкның эш графигы: һәр көнне, шимбә һәм якшәмбедән тыш, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш 13.00 сәгатьтән 13.45 сәгатькә кадәр.

Министрлыкның опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге тарафыннан гаризаларны кабул итү графигы: атна саен, һәр сишәмбе көнне 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, төшке аш 13.00 сәгатьтән 13.45 сәгатькә кадәр, эш көннәрендә 15.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр 8 (843) 294 95 67 телефоны буенча алдан язылып (сишәмбедән тыш).

Җәмәгать транспорты белән «Ирек мәйданы», «КАИ», «Үзәк стадион» тукталышына кадәр килергә кирәк.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

Белешмә телефоннары: 8(843) 294 95 67, 8(843) 294 95 66 эш көннәрендә 15.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, сишәмбедән кала.

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mon.tatarstan.ru.

1.3.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында(http://www.mon.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://gosuslugi.ru);

2) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

3) Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән mon@tatar.ru электрон адресына электрон документ формасында яки Министрлык сайтындагы интернет-кабул итү системасы аша «Мөрәҗәгатьләр» бүлекчәсендә);

1) дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Министрлыкның мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

5) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эшләү урыннарына мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.3. Министрлыкның урнашкан урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, КФҮ читтән торып эшләү урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Министрлыкның автоматлаштырылган идарә системалары һәм мәгълүмат куркынычсызлыгы бүлеге белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарында мәгълүмат стендларында дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 14 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында» 1996 елның 21 декабрендәге 159-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 159-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, №52, 5880 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, №31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, №15, 2036 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмә урынын торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмә раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, №6, 702 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган ятим һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм 23 яшенә җиткән балалар исәбендәге затлар исемлеген формалаштыру, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларны Россия Федерациясе субъектында элеккеге яшәгән урыны буенча исемлектән төшерү һәм аларны Россия Федерациясе субъектында яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү турында» 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2019, №15, 1764 статья);

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннар белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы ТРЗ) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, №1, 8 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар бирү тәртибе турында» 2007 елның 20 сентябрендәге 475 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2007, №39, 1489 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 елның 8 маендагы 287 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2009, №19-20, 0797 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннар белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү

хакында» 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2013 елның 4 маендагы 312 номерлы карары (алга таба – 312 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2013, №37, 1106 статья).

1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза – дәүләт хезмәте күрсәтү турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать. Гаризаларның киңәш ителә торган рәвешләре әлеге Регламентның 2 нче, 3 нче кушымталарында китерелде;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада да, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

«бер тәрәзә» принцибы – мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында тиешле рәсми мөрәҗәгать белән яки 210-ФЗ номерлы федераль законның 15' статьясында күрсәтелгән рәсми мөрәҗәгать белән бер мәртәбә мөрәҗәгать иткәннән соң дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтелә торган, ә дәүләт хезмәте күрсәтә торган органнар яки муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар белән хезмәттәшлек итү мөрәҗәгать итүче катнашыннан башка гына, норматив хокукый актларга һәм хезмәттәшлек итү турындагы килешүгә туры китереп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырыла торган принцип;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) – 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать. Гаризаның киңәш ителә торган формалары әлеге Регламентка карата 1 нче, 2 нче кушымталарында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атылышы | Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү (алга таба – Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлеге, Исемлек, ятим балалар). | |
| 2.2. Башкарма хакимият органы исеме | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык). | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Ятим балаларны Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү турында карар.<br>Ятим балаларны Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертүдән баш тарту турында карар.<br>Яши торган урыннары алмаштырылган очракта, Россия Федерациясенең башка субъектында исемлеккә кертелгән ятим балаларны Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү турында карар (алга таба – яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турында карар).<br>Яши торган урыннары алмаштырылган очракта, Россия Федерациясенең башка субъектында исемлеккә кертелгән ятим балаларны Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертүдән баш тарту турында карар (алга таба – яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар). | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 13 пункты, 34 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәте | Гаризаны теркәргә кимендә 60 эш көне кала Министрлык Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | балалар исемлегенә кертү (кертүдән баш тарту) турында карар кабул итә.<br>Исемлеккә кертү (кертүдән баш тарту) турында карардан өземтә, карар кабул ителгән көннән соң 5 эш көне эчендә, алынуын тәэмин итә торган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) җибәрелә.<br>Яңа яшәү урыны буенча Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар исемлегенә кертү турында карар Министрлык тарафыннан гариза теркәлгәннән соң 35 эш көне эчендә кабул ителә.<br>Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар исемлегенә кертүдән баш тарту турындагы карар Министрлык тарафыннан гариза теркәлгәннән соң 26 эш көне эчендә кабул ителә.<br>Яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертү яисә яңа яшәү урыны буенча исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар күчермәсе, аны кабул иткән көннән алып 5 эш көне эчендә, алынуын раслый торган ысул белән әлеге Регламентның 1.2.2 пунктында күрсәтелгән затларга, шулай ук элеккеге яшәү урыны буенча органга, шул исәптән бердәм ведомствоара электрон системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында да, җибәрелә.<br>Исемлеккә кертү турындагы гаризада (яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турындагы гаризада) һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тапшырган документлардагы, аларда булган белешмәләрдә төгәлсезлекләр һәм (яки) җитешсезлекләр булуы ачыкланган очракта, мәгълүматларны тәгаенләштерү турында Министрлык тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән көннән башлап әлеге рәсми мөрәҗәгатькә җавап алынган көнгә кадәр дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты туктатылып тора. Ятим балаларны Исемлеккә кертү турында карар кабул итү вакытын исәпләгәндә хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты исәпкә алынмый. | апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 12-13 пунктлары<br><br>РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 29-36 пунктлары |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон | 1. Исемлеккә кертү турында гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);<br>Исемлеккә кертү турында гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>ятим баланың тууы турында таныклык күчермәсе;<br>Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>торак урынның социаль найм килешү күчермәсе яисә социаль найм шартларында (булган очракта) торак урыннан файдалану хокукын раслый торган башка документлар (җирле үзидарә органнарында);<br>законлы вәкил вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе; | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 6, 7 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | ата-ананы (бердәнбер ата-ананы) югалтуны (булмавын) раслый торган документ күчермәсе (җирле үзидарә органында, гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);<br>мөрәҗәгать итүче вәкиленең Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе күчермәсе;<br>элек билгеләнгән торак урында яшәү мөмкинлеге булмавын раслый торган, Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән документлар;<br>2. Яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турында гариза (әлеге Регламентка 3 нче кушымта);<br>Яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турындагы гаризага түбәндәге документлар теркәлә:<br>ятим балаларның тууы турында таныклык күчермәсе;<br>ятим балаларның, балигъбулык яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алган ятим балаларның һәм ятим балалар исәбендәге затларның Россия Федерациясе гражданины паспорты күчермәсе;<br>опекун (попечитель) вәкаләтләрен раслый торган опека һәм попечительлек органы акты күчермәсе (җирле үзидарә органында);<br>балигъбулык яшенә җитмичә тулысынча хокуклылыкка ия булган ятим балалар опекунының, вәкиленең яки ятим балалар исәбендәге затлар вәкиленең законлы вәкилләренең Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе күчермәсе.<br>Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) исемлеккә кертү турында гариза тапшырганда Россия Федерациясе гражданины паспортын яки шәхесен таныклый торган башка документны (хәрби билет, хәрби билетка алмашка бирелә торган вакытлыча таныклык (хәрби хезмәт үти торган затлар өчен), паспорт рәсмиләштергән чорда бирелә торган Россия Федерациясе гражданины шәхесен таныклый торган вакытлы таныклык) яки чит ил гражданины яки Россия Федерациясендә шул сыйфатта танылып, гражданлыгы булмаган зат булып торган мөрәҗәгать итүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документны күрсәтә.<br>Мөрәҗәгать итүче документларның күчермәләрен тапшырмаган очракта, Министрлык аларны мөстәкыйль рәвештә әзерли.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 24, 25 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныклана.<br>Исемлеккә кертү турында гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тарафыннан Министрлыкка түбәндәгечә тапшырылырга мөмкин:<br>шәхсән;<br>почта элемтәсе ярдәмендә;<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яки Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып;<br>КФҮ аша. | |
| 2.6. Закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итә торган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча (Исемлеккә кертү турында гариза белән мөрәҗәгать иткәндә) түбәндәгеләр алына:<br>ата-ана (бердәнбер ата-ана) тәрбиясеннән мәхрүм калу (аларның булмавы) турында белешмәләр (җирле үзидарә органында, гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);<br>исемлеккә кертелергә тиешле затның исемлек төзелә торган Россия Федерациясе субъекты территориясендә яшәү урыны һәм (яки) торган урыны буенча теркәлүе турында белешмәләр (булган очракта) (вәкаләтле органда);<br>торак урынга милекчелек хокукының яки социаль найм килешүе буенча торак урыннан файдалану хокукы яисә социаль найм килешүе буенча наймга алучының гаилә әгъзасы сыйфатында торак урыннан файдалану хокукы булуы яки булмавы турында белешмәләр (җирле үзидарә органында, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсендә);<br>Гариза бирүче әлеге пункттагы белешмәләрдән торган документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны; | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торган, документларны һәм мәгълүмат тапшыруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче мәртәбә баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә), төгәлсезлеге һәм (яки) җитешсезлеге ачыкланган очракта, гаризадагы һәм тапшырылган документлардагы белешмәләрне тәгаенләштерү турында рәсми мөрәҗәгатьнең җибәрелүе дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору нигезе булып тора.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре каралмаган. | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 12 пункты, 29 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзен кабул итүне (хезмәт күрсәтелүне) көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артып китәргә тиеш түгел. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да | Рәсми мөрәҗәгать алынган көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә. | РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 11 пункты |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм | Дәүләт хезмәте янгынга каршы чичтема һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең интеграцияләнгән дәүләт системасына тоташтырылган мәгълүмат стендлары һәм мәгълүмат киосклары белән тәэмин ителгән биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыксыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15.1 статьясында каралган гаризаны (комплексны мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, җирле үзидарәнең үтәү-боеру | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык бүлмәләренең җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>Министрлык бинасының һәм бүлмәләренең инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген бирә торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин ителүе;<br>белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачау итүче каршылыкларны җиңәргә ярдәм күрсәтелүе;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозуына нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документлар почта аша җибәрелгәндә, – бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер мәртәбә | |

| | | |
|---|---|---|
| органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки аннан файдалана алмау | бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтәп торып эшләү урыннарында күрсәтелгәндә, күпфункцияле үзәк белгече, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарындагы белгечләр консультацияли һәм документларны кабул итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка, күпфункцияле үзәккә телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук «Интернет» челтәрендә Министрлык, күпфункцияле үзәк сайтыннан алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми. | |
| 2.16. Экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен дә исәпкә ала торган башка таләпләр | Консультация шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша (mon@tatar.ru) электрон хәбәр рәвешендә бирелергә мөмкин.<br>Электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре «Интернет» челтәреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин: Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яки «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтыннан файдаланып.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза һәм документлар күпфункцияле үзәк, читтән торып эшләү урыны урыны тапшырылган очракта, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, читтән торып эшләү урыны хезмәткәре консультацияли, документларны кабул итә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат бирә. | 63-ФЗ номерлы федераль закон;<br>210-ФЗ номерлы федераль закон |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин итәлергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, консультация бирү (хезмәт күрсәтү вакытына керми);

2) гариза һәм документларны кабул итү, теркәү

3) ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

4) ятим балаларның исәпкә алу эшләрен формалаштыру

5) Министрлык каршындагы ведомствоара торак комиссиясе утырышында документларны карау

6) ятим балаларны Исемлеккә кертү яки кертүдән баш тарту турында кәгазьдә карар әзерләү

7) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү).

8) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү.

Мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле, документларны туплау тәртибе һәм торак урыннар белән тәэмин итәлергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертү өчен гариза тапшыру турында консультация алу өчен, турыдан-туры телефон буенча, электрон почта (mon@tatar.ru) һәм (яки) хат белән Министрлыкның опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенә (алга таба – Бүлек) мөрәҗәгать итә.

Бүлек хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә торак урыннар белән тәэмин итәлергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертү өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация бирә, гариза бланкын бирә һәм, кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә, консультацияләр журналында язу теркәү.

3.3. Гариза һәм документларны кабул итү, теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) шәхсән, почта элемтәсе ярдәмендә, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан яки Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан файдаланып, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны

теркәп, Министрлыкка Исемлеккә кертү турында гариза (яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турында гариза) тапшыра.

Бүлек хезмәткәрләре мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча хаталарны бетерүдә ярдәм күрсәтә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләрен таныклый. Гаризаны һәм аңа беркетелә торган документларның таныкланган күчермәләрен канцеляриягә (420000, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 йорт) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны кабул итү һәм теркәү.

3.3.2. Министрлык хезмәткәре әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә.

Документларның тулы пакеты булган очракта, Министрлык хезмәткәре документлар белән гаризаны Комиссия утырышында карау өчен кабул итә.

Исемлеккә кертү турындагы гаризада һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тапшырган документларда булган мәгълүматларның төгәл һәм (яки) тулы булмавы ачыкланган очракта, Министрлык мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) әлеге мәгълүматларны тәгаенләштерү турында рәсми мөрәҗәгать җибәрә. Рәсми мөрәҗәгать мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) кул куйдыртып тапшырылырга, кулга тапшыру турында белдерүле заказлы хат итеп яки элемтәнең телекоммуникация каналлары буенча электрон формада җибәрелергә мөмкин

Исемлеккә кертү турындагы гаризада (яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турындагы гаризада) һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) тапшырган документлардагы мәгълүматларны, аларда булган белешмәләрдә төгәлсезлекләр һәм (яки) җитешсезлекләр булуы ачыкланган очракта, тәгаенләштерү турында Министрлык тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә) рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән көннән башлап әлеге рәсми мөрәҗәгатькә җавап алынган көнгә кадәр дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты туктатылып тора. Ятим балаларны Исемлеккә кертү турында карар кабул итү вакытын исәпләгәндә хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты исәпкә алынмый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар документлар кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүче вәкиленә) гаризадагы һәм мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тапшырган документлардагы мәгълүматларны тәгаенләштерү турында рәсми мөрәҗәгать җибәрү.

3.4. Ведомствоара мөрәҗәгатьләрне формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү.

3.4.1. Исемлеккә кертү турында гариза килгән очракта, Министрлык хезмәткәрләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша түбәндәгеләр турында белешмәләр бирү турында электрон формада рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

ата-ана (бердәнбер ата-ана) тәрбиясеннән мәхрүм калу (аларның булмавы) турында – җирле үзидарә органына, гражданлык хәле актларын теркәү органына;

исемлеккә кертелергә тиешле затның исемлек төзелә торган Россия Федерациясе субъекты территориясендә яшәү урыны һәм (яки) торган урыны буенча теркәлүе турында (булган очракта) – вәкаләтле органга;

торак урынга милекчелек хокукының яки социаль найм килешүе буенча торак урыннан файдалану хокукы яисә социаль найм килешүе буенча наймга алучының гаилә әгъзасы сыйфатында торак урыннан файдалану хокукы булуы яки булмавы турында – җирле үзидарә органына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы идарәсенә;

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче оешма белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгатьләр нигезендә сорала торган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда Министрлыкка бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап нәтиҗәсе булган мәгълүматлар (документлар) яки соралган белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.4.3. Яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турында гариза кергән очракта, Министрлык хезмәткәрләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада түбәндәге рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрә:

исәпкә алу эшен бирү турында (ятим балалар Исемлеккә кертелгән Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына (алга таба – элекеге яшәү урыны буенча вәкаләтле орган);

ятим балаларны билгеләнгән тәртиптә исәпкә кую турында (яңа яшәү урыны буенча опека һәм попечительлек органына).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.4. Ятим балаларны Исемлектән төшереп калдыру өчен 159-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясындагы $3^1$ пунктның 1, 2 һәм 4 пунктчаларында каралган нигезләр булу-булмавын тикшергәннән соң, кулга тапшыру турында белдерү белән заказлы хат итеп, исәпкә алу эшен Министрлыкка җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында каралган рәсми мөрәҗәгать килгән көннән башлап 20 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән исәпкә алу эше.

3.5. Исемлеккә кертү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән ятим балаларның исәпкә алу эшләрен формалаштыру.

Министрлык хезмәткәре ятим балаларның исәпкә алу эшләрен формалаштыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң 8 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: формалаштырылган исәпкә алу эшләре;

3.6. Министрлык каршындагы ведомствоара торак комиссиясе утырышында документларны карау.

3.6.1. Министрлык хезмәткәре Исемлеккә кертү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән ятим балаларның шәхси эшләрен шәхси эшләр формалаштырылганнан соң 1 календарь көне эчендә карау өчен Комиссиягә җибәрә.

Комиссия сәркатибе, Комиссия Рәисе белән килештерелгән ведомствоара торак комиссиясенең утырышлар графигы нигезендә, Комиссия әгъзаларына утырыш датасы һәм вакыты турында хәбәр итә.

Комиссия утырышлары Комиссия рәисе белән килештерелгән график нигезендә уза. Комиссия үз утырышында Татарстан Республикасыннан булган ятим балаларның, шулай ук Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән килгән ятим балаларның шәхси эшләрен карый һәм, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртипкә туры китереп, Татарстан Республикасында торак белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны Исемлеккә кертү турында карар кабул итә.

Торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге:

мөрәҗәгать итүченең 2013 елның 12 гыйнварындагы 8-ТРЗ номерлы ТР Законының 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бер генә категориясенә дә карамавы;

мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле документларның тапшырылмавы яки тулы күләмендә тапшырылмавы;

тапшырылган документларда ятим бала турында төгәл булмаган мәгълүматларның булуы.

Исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы карар торак урын бирү өчен 159-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясында каралган нигезләр булмаган очракта кабул ителә. Исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы актта, әлеге федераль законның тиешле нормасына сылтама ясап, мондый баш тартуның нигезе күрсәтелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертү (кертүдән баш тарту) турында карар.

3.6.2. Министрлык хезмәткәре яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән ятим балаларның шәхси эшләрен шәхси эшләр килгән көнне карау өчен Комиссиягә җибәрә.

Яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

159-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясындагы $3^1$ пунктының 1, 2 һәм 4 пунктчаларында каралган нигезләр булганда;

опека һәм попечительлек органы актында опекун яки попечитель билгеләнүе турында яисә опека яки попечительлек башкару турындагы килешүдә опекунга яки попечительгә тәрбиядәге затның яшәгән урынын үзгәртү тыелганлыгы турында ачыкланган очракта.

Исемлеккә кертүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Комиссия ятим балаларны яңа яшәү урыны буенча Исемлеккә кертү турында карар кабул итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пункты нигезендә җибәрелә торган рәсми мөрәҗәгатьләр буенча мәгълүмат алынган көннән башлап 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Россия Федерациясенең башка субъектында Исемлеккә кертелгән ятим балаларны, алар яшәү урынын үзгәрткәндә, Татарстан Республикасы махсус торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар Исемлегенә кертү турында карар.

3.7. Ятим балалар Исемлегенә кертү турында кәгазьдә карар әзерләү һәм җибәрү.

Министрлык хезмәткәре Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертү (кертүдән баш тарту) турында Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар турында кәгазьдә белдерү әзерли, аларны Комиссия рәисе белән килештерә.

Ятим баланы Исемлеккә кертү турында Комиссия тарафыннан кабул ителгән карар турындагы мәгълүматлар Исемлеккә керткән көннән соңгы эш көненнән соңга калмыйча Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына кертелә.

Татарстан Республикасының махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертү (кертүдән баш тарту) турында Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар турындагы мәгълүматлар мөрәҗәгать итүчеләргә кәгазьдә хат белән җибәрелә яки кул куйдыртып тапшырыла. Министрлык хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабат бирү яки Исемлеккә кертүдән баш тарту турындагы Комиссия карарына шикаять белдерү тәртибен аңлата.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.6.1, 3.6.2 пунктларында каралган процедуралар тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар Исемлегенә кертү (кертүдән баш тарту) турында карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза;

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил)

тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, «Интернет» челтәре ярдәмендә җибәрелә.

3.8.2. Бүлек белгече техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кигән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.8.3. Бүлек белгече җибәрелгән техник хатаны төзәтә. Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура җибәрелгән хата турында гариза алынган вакыттан башлап 14 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән техник хата.

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, карарлар кабул итүдән һәм Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләргә җавап әзерләүдән тора.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

- дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документларның проектларына хокукый экспертиза уздыру. Экспертизалар нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

- эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

- дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгатенә бәйле мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында министрга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар тапшырылырга мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контрольлек дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган белгеч, эш башкару хезмәте белгечләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге Министрлыкның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда, гаепле затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Җаваплы башкаручы мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамаган өчен җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1' өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр – күпфункцияле үзәк җитәкчесенә, күпфункцияле үзәк карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка белдерелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту очрагында, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mon.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып, КФҮ (http://mfc16.tatarstan.ru/) рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган дәлилләр.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә һәм Министрлыкның, күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы 5 эш көне эчендә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

5.7. Әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көн узганчы, мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык, күпфункцияле үзәк тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә. Шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

## 6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

6.1. Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать иткәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) гаризаны Министрлыкка җибәрү.

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, формасы буенча һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләрендә, һәм, зарурлык булганда, гариза бланкын тутырганда ярдәм күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турындагы мәгълүматны күпфункцияле үзәк (http://mfc16.tatarstan.ru/) сайтыннан ирекле файдалану юлы белән дә алырга мөмкин.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалануның башка мәсьәләләре буенча мәгълүмат.

6.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

6.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урынына документлар тапшыра.

6.3.2. Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган хезмәткәре күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.4. Гаризаны Министрлыкка җибәрү.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре гаризаны һәм тапшырылган документларны Министрлыкка җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Министрлыкның һәм күпфункцияле үзәкнең үзара хезмәттәшлек итү тәртибе Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында төзелгән 2018 елның 28 декабрендәге 66 номерлы үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешү нигезендә җайга салына, килешү Министрлык сайтында,

«Эшчәнлек/дәүләт хезмәтләре күрсәтү/Исемлеккә кертү» бүлегендә урнаштырылган, ә күпфункцияле үзәкнең мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү тәртибе КФҮ эш регламентында билгеләнгән.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында, Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасындагы үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән вакытларда, ләкин гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – Министрлыкка юлланган гариза.

6.5. Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү турындагы гаризаны күпфункцияле үзәккә шәхсән яки ышанычлы заты аша тапшыра.

Күпфункцияле үзәкнең гаризалар кабул итә торган хезмәткәре күпфункцияле үзәкнең эш регламентында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедуралар күпфункцияле үзәкнең эш регламентында билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәсе – техник хаталарны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

6.6. Техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Министрлыкка юллау.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре Министрлык белән күпфункцияле үзәк арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда, әмма гаризаны күпфункцияле үзәктә теркәгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны Министрлыкка җибәрә.

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына
кемнән______________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)
корреспонденция өчен адрес:____________________________

элемтә өчен телефон:___________________________________

Техник хатаны төзәтү турында
ГАРИЗА

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

Язылган:______________________________________________________________
__________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:_____________________________________________________
__________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегез һәм тишле үзгәрешләр кертүегез турында үтенәм:
___________________________ «_____» _____________
(документ исеме)

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында мәгълүматны түбәндәгечә язмача формада алырга риза

_________________ _____________________ ( ______________________)
(дата) (имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

Мөһер урыны (булган очракта)

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин итәлергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Форма Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 4 апрелендәге 397 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына
кемнән_______________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән, торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү турында

ГАРИЗА

Мин,________________________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

Россия Федерациясе гражданины паспорты яисә шәхесне раслаучы башка документ:
_____________________________________________________________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

түбәндәге адрес буенча яшәү (тору) урыны буенча теркәлгән: _______________________

Телефон номеры, электрон почта адресы:_________________________________________
(булган очракта күрсәтелә)

мин –

☐ ятим баланың яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланың законлы вәкиле,

☐ ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге эшкә яраклылык сәләте булмаган яки чикләнгән рәвештә хокукка сәләтле затның, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм 23 яшенә җиткән затлар исәбендәге затның законлы вәкиле;

☐ ятим бала яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, балигълык яшемә җиткәнче тулысынча хокуклылык алган бала булып торам, түбәндәге нигездә_________________________________
_____________________________________________________________________________,
(18 яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алу турындагы документ реквизитлары күрсәтелә)

☐ ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге зат,

☐ кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән зат,

☐ ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил булып торам, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән, торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә (алга таба – исемлек) кертү турында үтенәм

___________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

___________________________________________

(көн, ай һәм туган ел)

Россия Федерациясе гражданины паспорты:_______________________________________

(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

түбәндәге адрес буенча яшәү (тору) урыны буенча теркәлгән: ___________________________

яшәгән урын_______________________________________________________________

махсус шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС):______________________________

☐ чөнки ятим бала яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге зат социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы яки социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы гаилә әгъзасы яки торак урынның милекчесе булып тормый,

☐ чөнки ятим бала яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге зат социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы яллаучы, яисә социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы гаилә әгъзасы, яисә торак урын милекчесе булып тора һәм ул элек биләнгән торак урында яшәве мөмкин түгел дип танылган,

___________________________________________

(социаль найм килешүе, милек хокукын раслый торган документ реквизитлары)

___________________________________________

(элек биләнгән торак урында яшәүнең мөмкин булмавын тану турында карар кабул иткән органның атамасы, элек биләнгән торак урында яшәүнең мөмкин булмавын тану турында документ реквизитлары)

Махсуслаштырылган торак урыннарның найм килешүе буенча махсуслаштырылган торак фондыннан торак урынны _______________ елда бирү яхшырак.

(ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлардан аларга белем бирү оешмаларында, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, сәламәтлек саклау системасы учреждениеләрендә һәм законда билгеләнгән тәртиптә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оештырыла торган башка учреждениеләрдә тору вакыты тәмамланганнан соң, шулай ук һөнәри белем алуны тәмамлагач, яки чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтәү вакыты беткәч яисә җәзаларны үтәтү учреждениеләрендә булу вакыты тәгәлләнгәннән соң торак урын бирү турында язмача формалы гариза булган очракта күрсәтелә)

кайда_______________________________________________________________

(Россия Федерациясе субъекты законы белән мондый хокук билгеләнгән очракта, территориясендә торак урын бирү өстенлекле муниципаль берәмлекне күрсәтергә)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1.

2.

3.

4.

Мин,______________________________________________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта) күрсәтелә)

әлеге гаризада һәм мин тапшырган документларда булган үземнең персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә һәм куллануга ризалык бирәм.

Төгәл булмаган яки ялган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык булуы турында кисәтү алдым.

________________________________________

(имза, дата)

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына
кемнән_______________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән, торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә Татарстан Республикасында яңа яшәү урыны буенча кертү һәм Россия Федерациясенең башка субъектында элек яшәгән урын буенча исемлектән төшереп калдыру турында гариза

Мин,_____________________________________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

Россия Федерациясе гражданины паспорты яисә шәхесне раслаучы башка документ:
_________________________________________________________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

түбәндәге адрес буенча яшәү (тору) урыны буенча теркәлгән: ______________________

Телефон номеры, электрон почта адресы:___________________________________________
(булган очракта күрсәтелә)

мин –

☐ ятим баланың яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланың законлы вәкиле,

☐ ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге эшкә яраклылык сәләте булмаган яки чикләнгән рәвештә хокукка сәләтле затның, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган һәм 23 яшенә җиткән затлар исәбендәге затның законлы вәкиле;

☐ ятим бала яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, балигълык яшемә җиткәнче тулысынча хокуклылык алган бала булып торам, түбәндәге нигезендә___________________________________
_________________________________________________________________________,
(18 яшенә җитмичә тулысынча хокуклылык алу турындагы документ реквизитлары күрсәтелә)

☐ ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге зат,

☐ кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән зат,

☐ ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче вәкил булып торам, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән, торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә (алга таба – исемлек) Татарстан Республикасында яңа яшәү урыны буенча кертү турында үтенәм

______________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

______________________________________________
(көн, ай һәм туган ел)

Россия Федерациясе гражданины паспорты:______________________________
(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

түбәндәге адрес буенча яшәү (тору) урыны буенча теркәлгән: ____________________
яшәгән урын______________________________________________
махсус шәхси счетның иминият номеры (СНИЛС):______________________________

☐ чөнки ятим бала яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге зат социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы яки социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы гаилә әгъзасы яки торак урынның милекчесе булып тормый,

☐ чөнки ятим бала яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге зат социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы яллаучы, яисә социаль найм килешүе буенча торак урынны наймга алучы гаилә әгъзасы, яисә торак урын милекчесе булып тора һәм ул элек биләнгән торак урында яшәве мөмкин түгел дип танылган,

______________________________________________
(социаль найм килешүе, милек хокукын раслый торган документ реквизитлары)

______________________________________________.
(элек биләнгән торак урында яшәүнең мөмкин булмавын тану турында карар кабул иткән органның атамасы, элек биләнгән торак урында яшәүнең мөмкин булмавын тану турында документ реквизитлары)

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган балалар, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар исәбендәге һәм 23 яшенә җиткән затлар исемлегеннән түбәндәгене төшереп калдыру турында үтенәм ______________________________

______________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)

элек яшәгән урын буенча______________________________________
элек яшәгән (торган) урын буенча теркәлү адресы

әлеге Россия Федерациясе субъектында: ______________________________
(Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлегенең исеме)

Ятим баланың шәхси эше ______________________________________

______________________________________________

идарәсендә.

Махсуслаштырылган торак урыннарның найм килешүе буенча махсуслаштырылган торак фондыннан торак урынны _______________ елда бирү яхшырак.
(ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлардан аларга белем бирү оешмаларында, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында, сәламәтлек саклау системасы учреждениеләрендә һәм законда билгеләнгән тәртиптә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оештырыла торган башка учреждениеләрдә тору вакыты тәмамланганнан соң, шулай ук һөнәри белем алуны тәмамлагач, яки

чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтәү вакыты беткәч яисә җәзаларны үтәтү учреждениеләрендә булу вакыты тәгәлләнгәннән соң торак урын бирү турында язмача формалы гариза булган очракта күрсәтелә)

кайда__________________________________________________________________

(Россия Федерациясе субъекты законы белән мондый хокук билгеләнгән очракта, территориясендә торак урын бирү өстенлекле муниципаль берәмлекне күрсәтергә)

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1.

2.

3.

4.

Мин,__________________________________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта) күрсәтелә)

әлеге гаризада һәм мин тапшырган документларда булган үземнең персональ мәгълүматларымны эшкәртүгә һәм куллануга ризалык бирәм.

Төгәл булмаган яки ялган мәгълүматлар биргән өчен җаваплылык булуы турында кисәтү алдым.

________________________________________

(имза, дата)

Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

## Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, алар исәбендәге затларны, кайчандыр ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган һәм 23 яшенә җиткән һәм алар исәбендәге затларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле затлар исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

### Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Борһанов Рафис Тимерхан улы | 294-95-90 | mon@tatar.ru |
| Министр урынбасары<br>Әсәдуллина Алсу Мөнир кызы | 294-95-60 | mon@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге башлыгы<br>Васильева Венера Олеговна | 294-95-66 | Venera.Vasileva@tatar.ru |
| Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлегенең әйдәп баручы консультанты<br>Бегунова Светлана Григорьевна | 294-95-67 | Svetlana.Begunova@tatar.ru |

### Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Социаль өлкәдә хосусый-дәүләт партнерлыгын үстерү мәсьәләләре бүлеге башлыгы<br>(Җәббаров М.Ф.) | 264-76-65 | Marat.Zabbarov@tatar.ru |
| Социаль өлкәдә хосусый-дәүләт партнерлыгын үстерү мәсьәләләре буенча бүлекнең баш киңәшчесе<br>(Субаева Г.М.) | 264-76-77 | Gulshat.Subaeva@tatar.ru |